РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» июнь 2020 ел г. Альметьевск № 857

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 2170 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 17 декабрендәге 2170 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтада:

2 бүлекнең 2.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4. Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү:

- объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза кергән көннән алып биш эш көне эчендә.»;

2 бүлекнең 2.5 пунктындагы 9 пунктчасында «проект документациясе» сүзләреннән соң «, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 һәм 3.9 өлешләре нигезендә кертелгән үзгәрешләр исәпкә алынган проект документациясен дә кертеп» сүзләрен өстәргә».

2. Район Башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе М.Н. Гирфанов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ

Зак. № 305-2000